| Республика Татарстан | Татарстан Республикасы |
| --- | --- |
| Менделеевский городской Совет<br>Менделеевского<br>муниципального района | Менделеевск муниципаль районы<br>Менделеевск<br>шәһәр Советы |

РЕШЕНИЕ КАРАР

18.06.2025 Менделеевск ш. № 96

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советы карар кылды:

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча «Менделеевские новости» - «Менделеевск яңалыклары» район газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга. http://pravo.tatarstan.ru
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

Шәһәр Советы рәисе урынбасары: Н.Н.Сөләйманов